ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

08.04.2025 | с. Набережные Моркваши | № 4

2025 елның язгы чорында Яр буе Моркващы авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының тискәре климат шартлары барлыкка килгән чорда конструктив элементларының кимүен булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Яр буе Морквашы авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап күчәренә туры килә торган массасы 5 тоннадан артык булган транспорт чаралары хәрәкәтенә 2025 елның 8 апреленнән 30 апреленә кадәр вакытлыча чикләү кертергә (алга таба - язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү Россия Федерациясенең юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган "Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү" 3.12 юл билгеләрен урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының “Югары Ослан” муниципальара бүлеге ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне тикшереп торуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе ___________ К.Г.Саттарова